БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» 02 2022 ел № 129

Пассажирларда яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны яисә соңгы алты ай эчендә әлеге авыруны кичерү фактын раслый торган QR - кодлар булуын, коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация ясауга медицина ягыннан каршылыклар булуны раслаучы гамәлдәге шәхси QR - кодлар булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Пассажирларда яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны яисә соңгы алты ай эчендә әлеге авыруны кичерү фактын раслый торган QR - кодлар булуын, коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация ясауга медицина ягыннан каршылыклар булуны раслаучы гамәлдәге шәхси QR - кодлар булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов